МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ
И ИМУЩЕСТВЕННЫХ
ОТНОШЕНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ
МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.03.2019 Казан ш. № 95-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2017 елның 8 февралендәге № 237-р карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә (җир кишәрлекләре өлешләренә) мөнәсәбәтле сервитут урнаштыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Законнарга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә боерам:

«Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә (җир кишәрлекләре өлешләренә) мөнәсәбәтле сервитут урнаштыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2017 елның 8 февралендәге № 237-р карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә (җир кишәрлекләре өлешләренә) мөнәсәбәтле сервитут урнаштыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган тәкъдим ителгән үзгәрешләрне расларга.

**Министр** **А.К.Хамаев**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
13.03.2019 № 95-пр
карары белән расланды

«Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә (җир кишәрлекләре өлешләренә) мөнәсәбәтле сервитут урнаштыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2017 елның 8 февралендәге № 237-р карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә (җир кишәрлекләре өлешләренә) мөнәсәбәтле сервитут урнаштыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.4.1 подпунктның икенче абзацын түбәндәге җөмлә белән тулыландырырга:

«Гаризалар кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, Министрлык эшләгән сәгатьләрдә»;

1.4.4 подпунктта:

беренче абзацка «дәүләт хезмәте турында» дигән сүзләрдән соң «, шулай ук, Министрлыкның урнашу урыны һәм эш графигы турында» дигән сүзләрне өстәргә;

бишенче абзацта «(http://uslugi.tatar.ru/)» сүзләрен «(http://uslugi.tatarstan.ru)» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә бирелгән мәгълүмати стендлардагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктлардагы дәүләт хезмәте турындагы белешмәне үз эченә ала.»;

1.4.5 подпунктны көчен югалткан диеп танырга;

1.6 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«күпфункцияле үзәкнең дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче ераклаштырылган эш урыны – Татарстан Республикасының муниципаль районнардагы (шәһәр округында) шәһәр һәм авыл җирлекләрендә «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк эшчәнлеген оештыру тәртипләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге № 1376 карары белән расланган Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк эшчәнлеген оештыру тәртипләренең 34 нче пункты нигезендә оештырылган дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче

күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур подразделениесе (офис);»;

2 бүлектә:

2.4 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасындагы беренче абзацында утыз көн эчендә сүзләрен «унҗиде эш көне эчендә» дип алыштырырга,»

2.5 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«Гариза һәм аңа теркәлгән документларны гариза бирүче кәгазь форматта түбәндәге ысуллар белән тапшыра (җибәрә) ала:

шәхсән үзе (ышанычнамә нигезендә гариза бирүче исеменнән эш итүче зат);

почта аша.»;

2.6 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«Гариза бирүче әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләр булган документларны үзе тапшыра ала, шул исәптән, мөмкинлек булган очракта электрон формада да.

Гариза бирүченең өстә күрсәтелгән белешмәләр булган документларны тапшырмавы дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартуга сәбәп булып тормый.

Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларын алу һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән.

Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарында, башка дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы башка дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнарының ведомствосында булган һәм башка оешмаларда булган документларны. Искәрмә булып №210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә каралган документлар тора.

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда белешмәнең булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгәндә. Түбәндәге очраклар искәрмә булып тора:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында беренче тапкыр документлар тапшырганнан соң, дәүләт хезмәте күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәрү;

документлар кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң, дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатьтә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәткәндә зарури булган һәм алдан тапшырылган документлар комплектына кертелмәгән документларда хаталар булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәткәндә зарури булган документлар кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң, документларның срогы чыгуы яки мәгълүматның үзгәрүе;

дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, дәүләт хезмәткәренең дәүләт хезмәте күрсәтү өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәткәндә зарури булган документлар кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда хаталы яки хокукларга каршы гамәленең (гамәл кылмавының) документаль расланган факты (билгеләре) ачыклануы. Бу хакта гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесе имзасы куелган хат аша белдерелә, кыенлык тудырылуы өчен гафу үтенелә.»;

2.9 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Законнарда дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган.»;

2.13 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Электрон формада ял көне (бәйрәм көнендә) кергән запрос ял көненнән (бәйрәмнән) соң килгән эш көнендә регистрацияләнә»;

2.15 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Министрлык биналарының җәмәгать транспортына якын булуы;

Министрлык бинасын һәм бүлмәләрне инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелгән бүлмәләргә каршылыксыз үтү мөмкинлеге тудыра торган чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин итү;

инвалидлар өчен бүлмәләргә каршылыксыз үтү мөмкинлеге тудыру белән бәйле булмаган, башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтелергә комачаулаган башка барьерларны үтәргә булышу;

кирәк кадәр санда белгечләрнең, шулай ук, гариза бирүчеләрнең документларын кабул итә торган урыннарның булуы;

мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүматның булуы.

Дәүләт хезмәтенең сыйфаты күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау срогының саклануы;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогының саклануы;

Министрлык белгечләренең әлеге Регламентны бозулары турында нигезле шикаятьләрнең булмавы;

Гариза бирүченең министрлык белгечләре белән үзара бәйләнеш саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны биргәндә ике тапкырдан (консультацияләрне исәпкә алмаганда) да артмый;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – (консультацияләрне исәпкә алмаганда) бердән дә артык түгел.

дәүләт хезмәте күрсәткәндә белгеч белән гариза бирүченең бәйләнеш вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.

Дәүләт хезмәте күп функцияләр башкаручы үзәктә, күп функцияләр башкаручы үзәкнең дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган ераклаштырылган эш урыннарында күрсәтелми.

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүматны Министрлыкка телдән (шәхсән үзе яисә телефоннан) яки язмача мөрәҗәгать итеп, шулай ук Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайты аша белешә ала.»;

2.16 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасындагы беренче абзацка «Интернет» челтәрендәге» дигән сүзләрдән соң «№7 Боерык таләпләренә туры китереп» сүзләрен өстәргә»;

3 бүлектә:

3.1.1 подпунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә киткән техник хаталарны төзәтү.»;

3.1.2 подпунктын алтынчы абзацын «гариза һәм документлар электрон формада ял көне (бәйрәм көнендә) кергән очракталар искәрмә булып тора» сүзләре белән тулыландырырга;

3.4.1 подпунктның бишенче абзацында «дүрт көнлек» сүзләрен «бер эш көне эчендә» сүзләре белән алмаштырырга;

3.5.1 подпунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.1. Бүлек белгече әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән белешмәләр (декументлар) кергәннән соң түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

сервитут урнаштыру турында килешү төзүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә. Түбәндәге нигезләрнең берсе генә булса да, сервитут урнаштыру турында килешү төзүдән баш тарту өчен сәбәп булып тора ала:

1) сервитут урнаштыру турында мөрәҗәгать сервитут урнаштыру турында килешү төзергә хокукы булмаган башкарма хакимият органына юлланган;

2) җир кишәрлеген сервитут шартларында планлаштырылган файдалану федераль законнарга туры килми;

3) сервитут урнаштыру җир кишәрлеген рөхсәт ителгәнчә файдалану мөмкинлеген бетерә яки җир кишәрлеген куллануда каыенлыкларга китерә;

андый нигезләр булган очракта сервитут урнаштыру турында килешү төзүдән баш тарту турында карар проекты (алга таба – Баш тарту турында карар) яисә Гариза бирүче тәкъдим иткән чикләрдә сервитут урнаштыру турында килешү төзү мөмкинлеге турында белдерү проекты (алга таба – Белдерү), яисә территориянең кадастр планында сервитут чикләре схемасы беркетелгән, башка чикләрдә сервитут урнаштыру турында килешү төзү мөмкинлеге тәкъдиме проекты (алга таба – Тәкъдим) яки сервитут урнаштыру турында килешү проекты (Килешү) әзерләү;

Баш тарту турында карар проектын яисә Белдерү проектын, яисә Тәкъдим проектын яки Килешү проектын килештерү өчен Бүлек мөдиренә юллау.

Әлеге пункт билгеләгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Килештерү өчен Бүлек мөдиренә юлланган Баш тарту турында карар проекты яисә Белдерү проекты, яисә Тәкъдим проекты яки Килешү проекты.

3.5.2 подпунктның икенче абзацын көчен югалткан дип танырга;

3.5.3 подпунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентның 3.5.2, 3.5.3 пунктлар белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көн эчендә гамәлгә ашырыла.»;

3.5.5 подпунктның икенче абзацында «өч көнлек» сүзләрен «бер эш көне эчендә» сүзләре белән алмаштырырга;

3.5.6 подпунктның икенче абзацында «өч көнлек» сүзләрен «бер эш көне эчендә» сүзләре белән алмаштырырга;

3.5.8 подпунктның икенче абзацында «ике көндә» сүзләрен «ике эш көне эчендә» дип тулыландырырга;

3.5.10 подпунктның икенче абзацында «бер көн» сүзләрен «бер эш көне» дип тулыландырырга;

3.6.1 подпунктның икенче абзацында «бер көн» сүзләрен «бер эш көне» дип тулыландырырга;

3.6.3 подпунктның икенче абзацында второй «утыз» сүзен «календарь» сүзе белән тулыландырырга;

3.7.2 подпунктның икенче абзацында «егерме сигез көн эчендә» сүзләрен «ун эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

3.7.3 подпунктның икенче абзацында «бер көндә» сүзләрен «бер эш көне эчендә» дип тулыландырырга;

3.10.4 подпунктның икенче абзацында «өч көндә» сүзләрен «өч эш көне эчендә» дип тулыландырырга;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«5. Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү**

5.1. Гариза бирүчеләр Министрлыкның, Министрлыкның дәүләт хезмәт күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карарларыннан һәм кылган (кылмаган) гамәлләреннән зарланып Министрлыкка судка кадәрге тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

Министрның дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә

5.2. Гариза бирүче түбәндәге очракларда да шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар яки мәгълүмат таләп иткәндә, каралмаган гамәлләр кылуны сораганда;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүдән туктатып торганда, әгәр туктатып торуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән документларны һәм мәгълүматны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы яки дөрес булмавы күрсәтелмәгән очракта әлеге документларны һәм мәгълүматны таләп итү, № 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклар искәрмә булып тора.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) аша

җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган атамасы, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи зат яки карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерелгән дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы - булса), яшәү урыны турында белешмә, мөрәҗәгать итүче юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмә, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында белешмә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләре.

5.5. Гариза бирүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булса), яки аларның күчермәләрен тапшыра ала.

5.6. Шикаять, аны регистрацияләгәннән соң, унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш, аның вазыйфаи заты гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан баш тартуга яки ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акча средстволарын гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарту.

5.8. Әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм, гариза бирүченең теләгенә карап, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип табылса, әлеге Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган тәртип

бозуларны тиз арада бетерү максатыннан Министрлык башкарган гамәлләр хакында мәгълүмат бирелә, килеп чыккан уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен гариза бирүче кылырга тиеш гамәлләр билгеләп үтелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип табылмаса, әлеге Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карар турында дәлилле ачыклык кертелә, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелә

5.11. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча, административ хокук бозу билгеләре яки җинаять ачыкланса, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны тиз арада прокуратура органнарына юллый.»;

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә (җир кишәрлекләре өлешләренә) мөнәсәбәтле сервитут урнаштыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә (җир кишәрлекләре өлешләренә) мөнәсәбәтле сервитут урнаштыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Тәкъдим ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына
(кемнән) ________________________________________
(Ф.И.ӘИ (булганда) - физик затларга,
тулы атамасы,
оештыру-хокукый формасы -
юридик затларга)
________________________________________
(гариза бирүченең шәхесен таныклаган документ реквизитлары (гражданин өчен)
ИНН белешмәсе _____________________________
ОГРН/ОГРИП белешмәсе _____________________
Яшәү урыны (гражданин өчен), урнашкан урыны (юридик зат өчен) ______________________________
_______________________________________________
Телефон: _______________________________________
Почта адресы һәм (яки) электрон
почта адресы ____________________________________

Сервитут урнаштыру турында
МӨРӘҖӘГАТЬ

Җир кишәрелегенә сервитут урнаштыру турында килешү төзүегезне үтенәм

| | |
|---|---|
| Җир кишәрлегенең кадастр (шартлы) номеры: | |
| Адрес (ураншу урыны): | |
| Мәйданы: | |
| Сервитут урнаштырыла торган җир кишәрелегенең исәп номеры: | |
| Мәйданы: | |
| Сервитут урнаштырылу максаты: | |
| Сервитутның гамәлдә булу срогы | |
| Вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документның атамасы һәм реквизитлары: | |
| Мөрәҗәгатькә беркетелгән документлар: | Булуы билгесе |
| Гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ (гариза бирүченең вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта) | |
| территориянең кадастр планында сервитут схемасы (җир кишәрлегенең өлешенә сервитут урнаштырылу турында килешү төзелгән очракта) | |
| Физик зат булган гариза бирүченең яисә физик яки юридик зат вәкиленең шәхесен аныклаган документ | |
| Сервитут урнаштыру күздә тотылган җир кишәрлеге турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә (ЕГРН) | |
| * гариза бирүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛ өземтәсе | |
| * гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында ЕГРИП өземтәсе | |

“Персональ мәгълүматлар турында” 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законга туры китереп, мин 420043, ТР, Казан ш., Вишневский ур., 26 й. адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (оператор) персональ мәгълүматны эшкәртергә (әлеге гаризада күрсәтелгән персональ мәгълүматны җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңарту, үзгәртү), файдалану, тапшыру (тарату, бирү), блоклауны, бетерүне, юкка чыгаруны да кертеп, автоматлаштыру чаралары белән яки алардан башка кылынган гамәл (операция) яисә гамәлләр (операцияләр) белән эшкәртергә рөхсәт бирәм. Мәгълүматның дөреслеген раслыйм.

Әлеге килешү гариза имзаланган көннән башлап язма рәвештә килешүне кире соратып алган көнгә кадәр гамәлдә була.

Гариза бирүченең имзасы (_______№__________________________ышанычнамә буенча вәкил
_________________________________________/________________________/
(вәкилнең фамилия, имя, әтисе исеме, имзасы)

М.П. (мөһер булганда)

Гариза кабул ителде: "___"__________ 20__ г.
______/_________________/гаризаны алган белгечнең имзасы, фамилиясе, инициаллары)

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә (җир кишәрлекләре өлешләренә) мөнәсәбәтле сервитут урнаштыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Сервитут урнаштыру турында мөрәҗәгатькә теркәлгән документлар исемлеге

| Документның атамасы һәм реквизитлары | Битләр саны | |
|---|---|---|
| | Төп нөсхәләр | Күчермәләр |
| | | |
| | | |
| | | |
| | Барлыгы | Барлыгы |

«_______»______________
(кабул итү датасы)

Гариза бирүче (ышаныч язуы буенча вәкил)

_______________ ______________________
(имза) (фамилия, инициаллар)

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белгече

___________________________________________
(имза) (фамилия, инициаллар)

___________________________________________

Искәрмә: Бөтен документлар 1 нөсхәдә тапшырыла

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә (җир кишәрлекләре өлешләренә) мөнәсәбәтле сервитут урнаштыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында сервитут урнаштыру турында мөрәҗәгать үтү
бите

Гариза бирүче ________________________________________________

Теркәү (керү) номеры _________________________

| N п/п | Министрлыкның структур бүлекчәсе | Алыну датасы | Имза | Тапшырылу датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Эш башкару һәм контроль бүлеге | | | | |
| 2. | Җир ресурслары идарәсенең дәүләт җирләрен нәтиҗәле файдалану бүлеге белгече | | | | |
| | Килештерүләр: | | | | |
| 3. | Җир ресурслары идарәсенең дәүләт җирләрен нәтиҗәле файдалану бүлеге мөдире | | | | |
| 4. | Җир ресурслары идарәсе мөдире | | | | |
| 5. | Хокук идарәсе белгече | | | | |
| 6. | Хокук идарәсе башлыгы | | | | |
| 7. | Министрның беренче урынбасарының кабул итү бүлмәсе (документларны имзалау) | | | | |
| 8. | Эш башкару һәм контроль бүлеге (документларны рәсмиләштерү һәм теркәү) | | | | |

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә (җир кишәрлекләре өлешләренә) мөнәсәбәтле сервитут урнаштыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә (җир кишәрлекләре өлешләренә) мөнәсәбәтле сервитут урнаштыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы

Гариза бирүче

Гариза бирүче (аның вәкиле) әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар комплекты белән мөрәҗәгать тапшыра

Мөрәҗәгать, документлар/дәүләт кадастр исәбе турында белдерү (алга таба – документлар)

Эш башкару бүлеге белгече

Документлар кабул итү, документларны регистрацияләү, документларны аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булу-булмауга тикшерү (Бүлек белгече катнашында)

Документларны кабул итүдән баш тарту, кире кайтару

Гариза бирүче

Кабул ителгән, регистрацияләнеп бүлеккә юлланган документлар

Бүлек белгече

Министрлыкта документлар үтү битен тутыра һәм ТР УФНС, ТР Росреестр, ФБУ «ФКП РТ»га запрослар юллый

ТР УФНС, ТР Росреестр, ФБУ «ФКП РТ»га запрослар

Министрлык запрослары буенча ТР УФНС, ТР Росреестр, ФБУ «ФКП РТ» документлары

Бүлек белгече


Әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарта торган нигезләрнең булу-булмавын тикшерә; Баш тарту турында карар проекты яисә Белдерү проекты, Тәкъдим проекты яки Килешү проекты әзерли.

Баш тарту турында карар проекты яисә Белдерү проекты, Тәкъдим проекты яки Килешү проекты

Начальник Отдела

Баш тарту турында карар проекты яисә Белдерү проекты, Тәкъдим проекты яки Килешү проектын карый һәм килештерә.

Килештерелгән Баш тарту турында карар проекты яисә Белдерү проекты, Тәкъдим проекты яки Килешү проекты


Идарә башлыгы
Баш тарту турында карар проектын яисә Белдерү проектын, Тәкъдим проекты яки Килешү проектын килештерә
Килештерелгән Баш тарту турында карар проекты яисә Белдерү проекты, Тәкъдим проекты яки Килешү проекты
Бүлек белгече
Килештерелгән Баш тарту турында карар проекты яисә Белдерү проекты, Тәкъдим проекты яки Килешү проектын Хокук идарәсенә юллый.
Хокук идарәсенә юлланган Баш тарту турында карар проекты яисә Белдерү проекты, Тәкъдим проекты яки Килешү проекты
Хокук идарәсе белгече
Баш тарту турында карар проекты яисә Белдерү проекты, Тәкъдим проекты яки Килешү проектына хокукый экспертиза үткәрә
Бәяләмә проекты (кимчелекләр булганда), килештерелгән Баш тарту турында карар проекты яисә Белдерү проекты, Тәкъдим проекты яки Килешү проекты
Хокук идарәсе башлыгы
Бәяләмәне имзалый яки Баш тарту турында карар проектын яисә Белдерү проектын, Тәкъдим проектын яки Килешү проектын килештерә
Килештерелгән Баш тарту турында карар проекты яисә Белдерү проекты, Тәкъдим проекты яки Килешү проекты
Имзаланган бәяләмә
Бүлек белгече
Хокук идарәсе бәяләмәсендә күрсәтелгән кимчелекләрне бетерә һәм Баш тарту турында карар проектын яисә Белдерү проектын, Тәкъдим проектын яки Килешү проектын килештерү өчен хокук идарәсенә юллый
Килештерү өчен хокук идарәсенә юлланган Баш тарту турында карар проекты яисә Белдерү проекты, Тәкъдим проекты яки Килешү проекты
Хокук идарәсе башлыгы
Баш тарту турында карар проекты яисә Белдерү проекты, Тәкъдим проекты яки Килешү проектын килештерә
Килештерелгән Баш тарту турында карар проекты яисә Белдерү проекты, Тәкъдим проекты яки Килешү проекты
Бүлек белгече
Баш тарту турында карар проектын яисә Белдерү проектын яисә Тәкъдим проектын яки Килешү проектын кул кую өчен министрның беренче урынбасарына юллый
Имзалау өчен министрның беренче урынбасарына юлланган Баш тарту турында карар проекты яисә Белдерү проекты яисә Тәкъдим проекты яки

Министрның беренче урынбасары

Баш тарту турында карар проектын яисә Белдерү проектын яисә Тәкъдим проектын яки Килешү проектын имзалый һәм регистрация өчен Эш башкару бүлегенә юллый

Имзаланган Баш тарту турында карар яисә Белдерү яисә Тәкъдим яки Килешү

Эш башкару бүлеге белгече

Баш тарту турында карар яисә Белдерү яисә Тәкъдим яки Килешүне регистрацияли һәм гариза бирүчегә юллый

Гариза бирүчегә юлланган Баш тарту турында карар яисә Белдерү яисә Тәкъдим яки Килешү

Эш башкару бүлеге белгече

Гариза бирүчегә Баш тарту турында карарны яисә Белдерүне яисә Тәкъдимне яки Килешүне тапшыра

Гариза бирүчегә тапшырылган Баш тарту турында карар яисә Белдерү яисә Тәкъдим яки Килешү

Гариза бирүче

Сервитут урнаштырыла торган җир кишәрлеге өлеше турында дәүләт кадастр исәбе өчен кирәкле белешмәләр булган документларны әзерләү эшләрен гамәлгә ашыра һәм җир кишәрлегенең күрсәтелгән өлешенә дәүләт кадастр исәбе үткәрү өчен мөрәҗәгать итә, Министрлыкка сервитут урнаштырыла торган җир кишәрлеге өлеше турында дәүләт кадастр исәбе турында Белдерү юллый

Бүлек белгече

Ведомствоара запрослар юллый, Килешү проекты әзерли, билгеләнгән тәртиптә килештерә һәм кул кую өчен министрның беренче урынбасарына юллый

Министрның беренче урынбасарына имза кую өчен юлланган Килешү проекты

Министрның беренче урынбасары

Килешү проектына кул куя һәм регистрацияләү өчен Эш башкару бүлегенә юллый

Имзаланган Килешү

Эш башкару бүлеге белгече

Килешүне рәсмиләштерә һәм граиза бирүчегә юллый

Гариза бирүчегә юлланган Килешү

Гариза бирүчегә Килешүне бирә

Гариза бирүчегә тапшырылган Килешү

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә (җир кишәрлекләре өлешләренә) мөнәсәбәтле сервитут урнаштыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Тәкъдим ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына
(кемнән) ________________

**Техник хатаны төзәтү турында гариза**

________________________________________________________________________________
(юридик затның атамасы, физик затның Ф.И.ӘИ.(булганда))
______________________________________________________________________________,
(Ф.И.ӘИ.(булганда), вәкилнең вазыйфасы)
__________________________________________________________нигезендә эш итә
(вәкилнең вәкаләтләрен раслаган документ атамасы)

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә (җир кишәрлекләре өлешләренә) мөнәсәбәтле сервитут урнаштыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә киткән техник хатаның төзәтелүен үтенәм.

Сервитут урнаштырылу турында 20______елның «____»_________ №________ килешүендә;

гариза бирүче тәкъдим иткән чикләрдә сервитут урнаштыру турында килешү төзү мөмкинлеге турында Белдерүдә җир кишәрлеге урнашу схемасын раслау турында Министрлык килешүе «____»_________ 20______ел. №________;

башка чикләрдә сервитут урнаштыру турында килешү төзү турында Тәкъдим «____»_________ 20______ел. №________;

Түбәндәге документларны беркетәм:

1.
2.
3.

Гариза бирүче (гариза бирүчеләр) турында белешмә:

| | |
|---|---|
| Юридик зат өчен реквизитлар *(ОГРН, ИНН, адрес (урнашу урыны)* | |
| | |
| | |
| Физик зат өчен (юридик зат вәкиле) паспорт мәгълүматлары *(серия, номер, кем һәм кайчан биргән, подразделение коды, теркәлү адресы),* Яшәү урыны адресы (теркәлү адресы белән туры килмәгән очракта), ИНН | |
| Элемтә телефоны, почта адресы һәм (яки) электрон почта адресы | |
| Җир кишәрлеге турында белешмә | |
| Кадастр номеры | |
| Җир кишәрлеге урнашкан урын | |

Дәүләт хезмәте күрсәтелүе турында (күрсәтүдән баш тарту турында) мәгълүматны язмача алырга риза

_______________              __________________ ( __________________)
(дата)              (имза)       (Ф.И.ӘИ.(булса) )

М.П.(мөһер булса)

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә (җир кишәрлекләре өлешләренә) мөнәсәбәтле сервитут урнаштыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмәлек)

## Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә (җир кишәрлекләре өлешләренә) мөнәсәбәтле сервитут урнаштыру турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган һәм контрольдә тотучы вазыйфаи затларның реквизитлары

### Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр<br>Хамаев Азат Кыям улы | 221-40-00 | mzio@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары<br>Галиев Артур Ирек улы | 221-40-01 | mzio@tatar.ru |
| Җир ресурслары идарәсенең Дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге мөдире<br>Миндубаева Гүзәл Эдуард кызы | 221-40-30 | Guzel.Mindubaeva@tatar.ru |
| Канцелярия эшләрен алып бару һәм контрольдә тоту бүлеге мөдире<br>Румянцева Гөлнур Нияз кызы | 221-40-81<br>221-40-83 | Gulnur.Rumyanceva@tatar.ru |

### Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе мөдире<br>Мостафин Айрат Рафинант улы | 264-77-15 | Ayrat.Mustafin@tatar.ru» |